Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Сугышлы авыл җирлегенең
Юлтимер торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрбиләр; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500(Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

а) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:

- Юлтимер торак пунктында (Совет урамы, Игтисамовлар урамы)урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү;
- территориядә механикалаштырылган һәм кул белән үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, иске авария хәлендәге агачларны кисү (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

б) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Юлтимер т. п. юлларын кардан чистарту (Совет урамы, Игтисамовлар урамы);

«РИЗА» «КАРШЫ».

соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 221 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 115.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 115 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге составына керүче Юлтимер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрбиләр; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500(Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

а) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:

- Юлтимер торак пунктында (Совет урамы, Игтисамовлар урамы) урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү;

- территориядә механикалаштырылган һәм кул белән үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, иске авария хәлендәге агачларны кисү (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

б) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Юлтимер т. п. юлларын кардан чистарту (Совет урамы, Игтисамовлар урамы) сораулары буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова